

11 сентябрьдә VII Кончыгыш икътисади форумында хезмәт житәкчесе Анна Попова гриппка каршы вакцинация буенча Ботенроссия кампаниясен ача. Чара Роспотребнадзорнын ВЭФ-2023 стендында узган.
«Сегодня на стенде Роспотребнадзора мы объявляем старт прививочной кампании от гриппа для всей нашей дорогой, прекрасной страны и ее жителей», - сказала глава Роспотребнадзора.
Роспотребнадзор житәкчесе билгеләп vткәнчә, бvгенге кондә гриппка каршы вакцина Россия тобәкләренә, шул исәптән Мордовиягә дә китерелгән, ә прививка кампаниясенә әзерлек шактый югары.      Моннан тыш, Россия Федерациясенен Баш дәvләт санитар табибы карары нигезендә, быел да, элеккечә, Россия Федерациясенен гомуми халкынын ким дигәндә 60% һәм куркыныч торкемнәренен 75% прививка ясатырга кирәк. Риск торкемнәренә медицина һәм мәгариф тармагы хезмәткәрләре, олкәннәр, иммунитеты какшаган һәм хроник авырулары булган гражданнар, шулай ук кечкенә балалар керә. Шулай ук 1 октябрьгә кадәр тобәкләр медицина оешмаларынын авырулар кvтәрелv чорында эшләргә әзерлеген бәяләргә тиеш. Даруханә челтәрендә һәм медицина оешмаларында вирусларга каршы дарулар, дезинфекция чаралары һәм шәхси саклану чаралары запасын киметмичә саклауны тәэмин итәргә кирәк, ди Роспотребнадзор житәкчеләре.
Мордовиядә гриппка каршы вакциналарны авылларда да, республикабыз шәһәрләрендә дә халыкка сала башладылар инде.
Коз коне гадәттәгечә вируслы авырулар баш калкытып килә. Бәрәнге алу, уныш жыю, бакчаларны чистарту белән vрелеп барган чорда тычкан бизгәге йоктыру очраклары да арта. Шуна кvрә белгечләр быел да уяулыкны югалт-маска чакыра. Әлеге чирне, нигездә, кыр тычканнары тарата. Алар авыру тычканнын токереге, тизәк-бәвеле яткан те-ләсә-кайсы жиргә кагылуга ук йогарга момкин. Шуна кvрә сарай, бакчада эш-ләгәндә, учакка утын жыйганда, салам ойгәндә аеруча игътибарлы булырга кирәк. Ашар алдыннан кулларны яхшылап юарга да онытмагыз дип кисәтә белгечләр.
Коз быел жылысы белән шатландыра. Хәзер бездә талпаннар очен янә унай шартлар саклана. Шуна кvрә сентябрьдә алар кабат актив рәвештә һожvм итә башларга момкин. Шуна кvрә алардан зыян кvрvчеләр саны артыр дип фаразлый табиблар ачык челтәрләрдә. Билгеле булганча, талпаннар боррелиоз, энцефалит кебек житди чирләр дә тарата. Билгеле булганча, әлеге чирләр баш миенә зур зыян сала. Шул рәвешле козен мул уныш белән беррәттән чирләрне дә мулдан жыймас очен уяулыкны югалт-маска кирәк.

**Н.ХӘЛИЛ әзерләде**